МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

20.03.2023 № 77

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы эшләре Министрлыгының 25.06.2018 № 376 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел 26 нчы гыйнвар № 1-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Администрациясе турында» 2023 ел 4 нче февраль № ПУ-68 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының норматив хокук актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнар оборонасы эшләре Министрлыгының (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) 25.06.2018 № 376 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә алдагы үзгәрешне (Татарстан Республикасы ГТХМ 26.02.2020 № 76 һәм 16.03.2021 № 103 боерыклары белән кертелгән үзгәреш белән) кертергә:

2 нче бүлекнең 2.4 пунктының беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты» сүзләренә алыштырырга;

I бүлектә 25.06.2018 № 376 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган Нигезләмәгә № 4 Кушымтаны «Сынау»:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сынау Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган сынау методикасы нигезендә башкарыла.».

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ министр урынбасарларына, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын
башкаручы Т.В. Кәримуллин